**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 24 апрелендәге 1356 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2007 елның 27 апрелендәге 841 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе каршындагы Җирдән файдалану һәм төзелеш комиссиясе турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе каршындагы Җирдән файдалану һәм төзелеш комиссиясе эшчәнлеген хокукый җайга салуны камилләштерү, норматив хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2007 елның 27 апрелендәге 841 номерлы карары белән расланган Казан шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе каршындагы Җирдән файдалану һәм төзелеш комиссиясе турындагы нигезләмәгә (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2018 елның 8 июнендәге 3396 номерлы, 2019 елның 16 декабрендәге 4492 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.7 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«3.7. Комиссиянең җаваплы секретаре:

3.7.1. Комиссия үз функцияләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле документларны әзерли;

3.7.2. Комиссиягә кергән тәкъдимнәр, искәрмәләр, үтенечнамәләр нигезендә Комиссиянең эш планын әзерли һәм аны раслау өчен Комиссия рәисенә җибәрә;

3.7.3. Комиссия утырышларын әзерли, Комиссия утырышының көн тәртибен Комиссия әгъзаларына җиткерә, Комиссия әгъзаларына чираттан тыш утырышлар турында, утырышларны башка срокка күчерү турында хәбәр итә;

3.7.4. гамәлдәге законнарда билгеләнгән очракларда, күчемсез милек объектларының хокук ияләренә һәм башка кызыксынган затларга иҗтимагый фикер алышулар уздыру турында хәбәрләр җибәрә;

3.7.5. беркетмәләрне һәм бәяләмәләрне, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында билгеләнгән вакыт эчендә, Комиссия утырышын уздырган көннән алып 5 эш көненнән дә соңга калмыйча рәсмиләштерә һәм имзалый;

3.7.6. Комиссиянең тәкъдимнәрен рәсмиләштерә;

3.7.7. иҗтимагый фикер алышулар нәтиҗәләре турындагы бәяләмәләрне һәм Комиссия әзерләгән башка документларны бастырып чыгаруны оештыра»;

1.2. 4.6 пунктта түбәндәге сүзләрне төшереп калдырырга:

«Комиссия утырышында рәислек итүче һәм Комиссиянең җаваплы секретаре тарафыннан имзалана торган».

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**